КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № б-2523

1. Татарстан Республикасында балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 23 ноябрь, б-2523 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы территориясендә балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) күмәк киңәшмә орган булып тора.

2. Эшче төркем Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча хөкүмәт комиссиясе тарафыннан расланган 2025 елга кадәр балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, әмма Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата торгызыла торган суд эшчәнлеген башкару максатларында медиация хезмәтләре челтәрен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча комплекслы чараларның 2019 елның 25 сентябрендәге 23 номерлы ведомствоара планындагы 4 пункт нигезендә оештырылган.

3. Эш төркеме үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Эшче төркемнең төп бурычлары:

а) медиация хезмәтләре челтәрен үстерү кысаларында үткәрелә торган һәм балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, әмма Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата торгызыла торган суд эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру проблемалары һәм практикасы буенча фикер алышу;

б) Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча хөкүмәт комиссиясе тарафыннан расланган 2025 елга кадәр балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, әмма Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата торгызыла торган суд эшчәнлеген башкару максатларында медиация хезмәтләре челтәрен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча комплекслы чараларның 2019 елның 25 сентябрендәге 23 номерлы ведомствоара планын гамәлгә ашыру ысулларын һәм формаларын билгеләү;

в) медиация хезмәтләре челтәрен үстерү кысаларында үткәрелә торган чараларны тормышка ашыру, шулай ук балигъ булмаганнарга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият

органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру.

5. Йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

а) федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар соратып алырга;

б) үз утырышларына федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның вазыйфаи затларын чакырырга;

в) федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар тарафыннан үткәрелә һәм Татарстан Республикасы территориясендә балигъ булмаганнарга карата медиация процедурасын куллануга кагылышлы мәсьәләләр тикшерелә торган чараларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

г) үз эшенә балалар белән эшләү өлкәсендәге белгечләрне җәлеп итәргә.

6. Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана. Эшче төркем аның җитәкчесе, җитәкче урынбасары, секретаре һәм әгъзалары составында төзелә. Эшче төркем утырышлары, әгәр дә аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала. Эшче төркем карарлары анда катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

7. Эшче төркем җитәкчесе эш төркеме эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра, эшче төркем җитәкчесе урынбасары, эшче төркем секретаре һәм эшче төркем әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, эшче төркем утырышларының көн тәртибен раслый, эшче төркем утырышларында рәислек итә, эшче төркем тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

8. Эш төркеме җитәкчесе урынбасары эшче төркем җитәкчесе булмаганда аның вазыйфаларын башкара, шул исәптән эшче төркем утырышларында рәислек итә, эшче төркем утырышларының көн тәртибен формалаштыра, эшче төркем әгъзаларына эшче төркем утырышын үткәрү урыны, датасы, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә.

9. Эшче төркем секретаре:

эшче төркем утырышларына материаллар, шулай ук карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

эшче төркем әгъзаларына һәм чакырылган затларга эшче төркемнең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны барлык кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

эшче төркем утырышы беркетмәсен алып бара.

10. Эшче төркем утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр, шулай ук кирәк булуга карап үткәрелә.

11. Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүченең имзасы куела.

12. Эшче төркем карарлары киңәш бирү характерында була.

13. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 23 ноябрь, б-2523 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында балаларга, шул исәптән җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган, Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Хәбибрахманова Ләйлә Фоат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариатының баш киңәшчесе, эшче төркем секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Вәлиев Айрат Мәгъдүт улы | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча өченче бүлек җитәкчесе (килешү буенча) |
| Васильева Венера Олеговна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| Волынец Ирина Владимировна | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Галимов Айнур Газинур улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Участок вәкаләтле полициясе һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру идарәсе баш белгече, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Герасимова Вера Вадимовна | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының психологик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| Кисиль Надежда Петровна | «Ябык типтагы Раифа махсус укыту-тәрбия бирү учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Кладов Дмитрий Юрьевич | «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус укыту-тәрбия бирү һәм гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Леонтьева Татьяна Ивановна | Татарстан Республикасының «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Овчинникова Елена Владимировна | Казан шәһәренең яшьләр сәясәте буенча «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Осипова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Участок вәкаләтле полициясе һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Охотникова Дарья Сергеевна | Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Яруллина Лилия Наил кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының балаларга өстәмә белем бирү бүлеге башлыгы. |